2.2. Килешү Заказ бирүче белән һәр очракта срогын күрсәтеп аерым төзелә һәм түбәндәгеләр күз алдында тотыла: атамасы, эш төрләре, күләме һәм хезмәткә түләү шартлары, билгеле бер вакыты һәм хезмәт күрсәтү сроклары, килешү төзүчеләрнең хокук һәм бурычлары, килешүнең үзгәрү тәртибе һәм килешүне өзү очраклары, бәхәсне чишү юллары, аерым шартлар. Килешүдә күрсәтелгән вакытта түләүнең бәясе турында өстәмә рәвештә аерым килешү дә төзелергә мөмкин. Килешү отчет документы булып санала һәм белем бирү оешмасында 5 елдан да ким сакланмаска тиеш.

2.3. Үтәүче Заказ бирүче белән килешүне түләүле хезмәт соралган очракта һәм аны күрсәтә алган очракта төзи, аерым бер физик яки юридик затка, Россия Федерациясе законнары һәм бүтән норматив хокукый актлар белән каралмаса, өстенлек бирелә алмый.

2.4. Үтәүче Заказ бирүченең (укучының) теләге буенча түләүле хезмәт нәтиҗәсе итеп укучыга белешмә (справка) бирә, анда белем бирү программасы, уку циклы яки фән (фәннәр), аларның сәгать саны күрсәтелә.

2.5. Килешү нигезендә түләү Заказ бирүче тарафыннан Үтәүченең счетына, түләү документларында күрсәтелгән счетка, акча күчерү юлы белән башкарыла.

3. Оешма түләүле белем бирә ала.

3.1. Нигезләмәнең 3 өлешендә күрсәтелгән шартлар булса, оешмага түләүле белем күрсәтү өчен түбәндәгеләр кирәк:

3.1.1. Түләүле белем бирүнең кирәклеген һәм укучыларның контингентын өйрәнү.

3.1.2. Түләүле белем бирүнең һәр төре буенча белем бирү программасы, уку планнары, дәресләр тәртибен төзү һәм раслау. Түләүле белем бирүгә тиешле сәгать саны һәм Заказ бирүчегә тәкъдим ителгән сәгатьләр саны. Түләүле белем бирүнең төрләре Заказ бирүченең яшенә һәм шәхси үзенчәлекләренә туры килергә тиеш, шул ук вакытта муниципаль заказ кысаларында белем бирүгә зыян китермәскә тиеш. Аерым очракларда, Заказ бирүченең теләге буенча, аның мөмкинлекләрен һәм сәләтен исәпкә алып, шәхси уку планы төзелергә мөмкин.

3.1.3. Заказ бирүченең документларына, түләүле белем бирү хезмәтендә, түбәндәге таләпләр куела: заказ бирүченең гаризасы, медицина бәяләмәсе (кайбер түләүле хезмәт төрләре өчен, хореография, спортның кайбер төрләре өчен), белемнең дәрәҗәсен билгеләүче документ, Заказ бирүченең шәхесен исбатлаучы документ). Әгәр Заказ бирүчегә 14 яшь тулмаган булса, аның исеменнән гаризаны әтисе яки әнисе бирә (законлы вәкил).

3.1.4. Һәр дәрес өчен айлык түләүне түләүле хезмәт күрсәтүнең расланган программасыннан чыгып, дәрес санын исәпкә алып, уку планы, түләүле белем бирүнең расланган тарифлары нигезендә башкарырга.

3.1.5. Түләүле белем бирү хезмәте алырга теләүче Заказ бирүчедән тиешле документларны алырга, һәм аның белән түләүле хезмәт килешүе төзергә (алга таба – Килешү). Әгәр Заказ бирүчегә Килешү төзегән вакытта 14 яшь тулмаган булса, аның исеменнән Килешүне әтисе яки әнисе (законлы вәкил) төзи.

3.1.6. Түләүле белем бирү хезмәте күрсәтү турында боерык чыгарырга, бу хезмәтне күрсәтүче хезмәткәрләрнең составын билгеләргә, оештыру-методик ярдәм күрсәтүче һәм хезмәт итүче кешеләрне билгеләргә, дәресне үткәрү бүлмәләрен, белем бирү программаларын, уку планын, дәресләр тәртибен, бүтән шарт һәм критерийларны – белем бирү оешмасы каравы буенча билгеләргә.

3.1.7. Оешманың хезмәткәрләре белән тиз арада хезмәт килешүе төзергә, шул исәптән читтән килеп эшләүчеләр, төп хезмәтеннән бушаган вакытта түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтергә теләүчеләр белән, педагогик хезмәткәрләргә түләүле хезмәт күрсәтүдән кергән акчаларга тарификация уздырырга. Түләүле белем бирүгә Үтәүче башка оешмалардан да белгечләрне чакыра ала, алар белән гражданлык – хокукый актлар түләүле хезмәт күрсәтүдән кергән акчаларга төзелә.

3.1.8. Педагогик хезмәткәрнең аерым эш вакытын исәпкә алу төп эш урынında расланган бюджет буенча, һәм түләүле хезмәт күрсәтүче педагогик хезмәткәрләргә аерым алып барыла.

3.1.9. Муниципаль бюджет тарафыннан финансланучы төп белем бирү тармагына һәм түләүле белем бирү хезмәтенә тотылучы материаль чыгымнарны аерым исәпләргә.

3.1.10. Үтәүче Заказ бирүчегә “Кулланучылар хокукын яклау” РФ Законы һәм “Россия Федерациясендә белем турында” Федераль Законында каралган бөтен төр мәгълүматны: түләүле белем бирү хезмәте күрсәтү, тәртибе һәм күләме җиткерергә тиеш.

3.2. Үтәүче Заказ бирүче таләбе буенча түбәндәге документларны күрсәтергә бурычлы:

- белем бирү оешмасының уставы;
- белем бирү оешмасының учредителе турындагы мәгълүмат;
- түләүле белем бирү хезмәте күрсәтү турында килешүнең үрнәге;
- Үтәүче тарафыннан күрсәтелгән түләүле белем бирү хезмәтенең расланган тарифы;
- Заказ бирүче таләбе буенча килешүгә караган һәм түләүле белем бирү хезмәте буенча документларны.

Санап кителгән мәгълүмат тулы түгел. Үтәүче Заказ бирүчегә түләүле белем бирү хезмәтенә караган һәм документ турында хәбәр итә. Үтәүче Заказ бирүчегә “Кулланучылар хокукын яклау” РФ Законы нигезендә мәҗбүри рәвештә хезмәт күрсәтүче җаваплы кешене төгәл атый, түләүле белем бирү хезмәтенең сыйфатына йогынты ясаса, аның турында мәгълүмат бирә.

3.3. Түләүле белем бирү хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы администрациясенең официаль сайтында, Интернет челтәрендәге белем бирү оешмаларының сайтларына куела. Заказ бирүчегә мәгълүматны түбәндәге юллар белән дә

биреп була: белдерү, буклет, проспект, иң яхшы укучыларның эшләре, мөгаллимнәрнең сыйныфтан тыш эшләре һ.б.

3.4. Үтәүче мәгълүматның ачык һәм аңлаешлы булуын тәэмин итәргә тиеш:

- Заказ бирүче акчасы белән белем алучы укучыларның санын;

- түләүле белем бирү хезмәте күрсәтүче педагогик хезмәткәрләрнең санын, аларның белем дәрәҗәсе, квалификациясе һәм эш тәҗрибәләре;

- белем бирү оешмасының түбәндәге локаль норматив актлары: түләүле белем бирү хезмәте күрсәтү тәртибе һәм түләүле белем алу өчен түләнгән акчаларның сарыф ителүе; түләүле белем бирү хезмәте күрсәтү турында килешүнең үрнәге, һәр түләүле белем бирү хезмәтенең расланган тарифлары документы.

3. 5. Түләүле белем бирү хезмәте күрсәтүнең һәр төре буенча белем бирү оешмасының шөгыльләрне календарь-тематик планлаштыру белән программалары булырга һәм ул белем бирү оешмасының җитәкчесе тарафыннан расланган булырга тиеш.

3.6. Белем бирү оешмасы сыйфатлы түләүле белем бирү максатыннан, төп укыту процессына кимчелек китермичә, СанПИН 2.4.2.2821-10, 2.4.1.3049-13, 2.4.4.3172-14 таләпләренә туры китереп, Заказ бирүченең тормышына һәм сәламәтлегенә гарантия биреп, материаль – техник һәм укыту базасы белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Түләүле белем бирү өчен дәресләр тәртибе нигезендә төп белем эшчәнлеге кысаларында уку оешмасының укыту һәм башка бүлмәләрен кулланырга мөмкин.

3.7. Белем бирү оешмасының уставында мәҗбүри рәвештә түләүле белем бирү мөмкинлеге, аның тәртибе күрсәтелергә тиеш.

3.8. Түләүле белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыру өчен белем бирү оешмасының түбәндәге локаль актлары булырга тиеш:

3.8.1. Түләүле белем бирү хезмәте күрсәтү һәм чыгымнар турында Нигезләмә (әгәр түләгән вакытта льготалы түләү булса, Нигезләмәдәге исемлектә льготаның күләме һәм тәртибе күрсәтелә)

3.8.2. Түләүле белем бирү турында (күрсәтелгән хезмәтләрне санап һәм төрен күрсәтеп, һәр хезмәтнең бәясен, төркем санын һәм укучылар санын, укыту сәгатьләр санын, бу төр хезмәтне оештыручы җаваплы кешеләрне күрсәтеп, һәр төр хезмәт буенча дискриминация коэффициентын күрсәтеп) Мәгариф идарәсе рәисе белән килештерелгән белем бирү оешмасы җитәкчесенең боерыгы.

3.8.3. Түләүле һәр төр хезмәт күрсәтү буенча түләү тарифы.

3.8.4. Муниципаль белем бирү оешмасы җитәкчесе раслаган белем бирү программалары, укыту планнары, дәресләр тәртибе.

3.8.5. Турыдан – туры түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүче һәм шартлар тудыручы штат хезмәткәрләренең дәресләр тәртибе (административ һәм техник персонал).

3.8.6. Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүче белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең хезмәткә түләү турындагы Нигезләмә, яки белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең хезмәткә түләү турындагы Нигезләмәгә өстәмә бүлек.

3.8.7. Стимул рәвешендә түләнә торган өстәмәләр, я (яки) белем бирү оешмасы хезмәткәрләренә түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүдән кергән акчалардан премия бирү.

3.9. Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүдән кергән кертемнәр, чыгымнар белем бирү оешмасының финанс – хуҗалык эшчәнлеге Планында чагылыш таба.

4. Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүнең тарифларын формалаштыру, түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүгә киткән чыгымнар

4.1. Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүнең тарифлары һәр түләүле хезмәт нигезендә салым һәм җыемнарны исәпкә алып, экономик яктан нигезләнеп формалаштырыла; шулай ук белем бирү процессының һәм материаль базаның үсеше, камилләшүе дә күздә тотыла. Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүнең тарифлары Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүнең тарифларын формалаштыру Нигезләмәсе (Нигезләмәнең №2 искәрмәсе) нигезендә тормышка ашырыла.

4.2. Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүнең түләү тарифы формасы

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән (Нигезләмәнең № 3 искәрмәсе) нигезендә раслана. Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүнең түләү тарифы чираттагы елга раслана һәм уку елы дәвамында үзгәрешсез кала.

4.3. Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүгә тотылган чыгымнар белем бирү оешмасының финанс – хуҗалык эшчәнлеге Планы нигезендә бюджет белем бирү оешмалары өчен Муниципаль казна учреждениесе “Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» раславы белән тормышка ашырыла.

4.4. Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүдән кергән акча берәмлекләре (алга таба - алган керемнәр) түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүгә тарифлар нигезендә бүленә. Оешманың үсеше өчен булган фондтагы акча берәмлекләре белем бирү оешмасы Нигезләмәсе нигезендә тотыла, ул Муниципаль казна учреждениесе “Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» тарафыннан раслана.

4.5. Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүче белем бирү оешмалары эшчәнлекләрен Муниципаль казна учреждениесе “Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» хисап алу килешүе нигезендә түләүле белем бирү хезмәтен исәпкә алу өчен документ булдыралар.

4.6. Заказ бирүчеләр тарафыннан түләү кредит оешмалары тарафыннан акча күчерү юлы белән тормышка ашырыла.

5. Якларның җаваплылыклары оешма һәм түләүле хезмәт күрсәтүгә контроль.

5.1. Башкаручы Килешүдә күрсәтелгән тәртиптә, срокта, устав, белем бирү оешмасының лицензиясе, Нигезләмә, оешмада түләүле белем бирү локаль норматив акт нигезендә түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтә.

5.2. Үтәүче һәм Заказ бирүче Килешүдә күрсәтелгән йөкләмәләрне үтәмәсә яки өлешчә генә үтәсә, Россия Федерациясе законнары буенча җавапка тартылалар.

5.3. Үтәүче Түләүле белем бирү хезмәте Килешүендә күрсәтелгән йөкләмәләрне үтәмәсә яки өлешчә генә үтәсә, үти алмаслык көчләр нәтиҗәсендә икәнлеген исбатлый алса, Россия Федерациясе законнары буенча җаваплылыктан азат ителә.

5.4. Заказ бирүче, әгәр белем бирү программалары буенча (белем бирү программасының бер өлеше) Түләүле белем бирү хезмәте Килешүендә күрсәтелгән йөкләмәләр үтәлмәгән яки өлешчә генә үтәлгән дип санаса, Заказ бирүче үз сайлавы буенча таләп итә ала:

- белем бирү программалары, укыту планы һәм Килешү буенча Түләүле белем бирү хезмәтен түләүсез рәвештә күрсәтүне;
- түләүле белем бирү хезмәтенең бәясен киметүне;
- түләүле хезмәт күрсәтүдә булган кимчелекләрне үз көчләре яисә башка затлар тарафыннан бетерү буенча тотылган чыгымнарны кайтаруны.

5.5. Заказ бирүче әгәр белем бирү программалары буенча (белем бирү программасының бер өлеше) Түләүле белем бирү хезмәте Килешүендә күрсәтелгән йөкләмәләр күрсәтелгән срокта үтәлмәгән очракта Килешүне өзә ала. Заказ бирүче Килешүдә күрсәтелгән йөкләмәләр үтәлмәгән очракта Килешүдән баш тарта ала.

5.6. Әгәр Башкаручы Түләүле белем бирү хезмәте Килешүендә күрсәтелгән срокны бозса (Түләүле белем бирүнең башы яки ахыры), Заказ бирүче үз сайлавы буенча түбәндәгеләрне сайлый ала:

- Башкаручыга Түләүле белем бирү хезмәтен башларга яки тәмамларга яңа срок билгели;

- өченче затка билгеле бер күләмдә акча бәрабәренә Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүне тапшыра һәм башкаручыдан шул бәяне кире кайтаруны сорый;

- Түләүле белем бирү хезмәтенең бәясен киметүне сорый ала;

- Килешүне өзә ала.

5.7. Заказ бирүче Башкаручыдан Түләүле белем бирү хезмәте Килешүендә күрсәтелгән срокны бозса (Түләүле белем бирүнең башы яки ахыры), белем бирү тулы күләмдә булмаса, тулы бәяне кайтаруны сорый ала.

5.8. Башкаручы тарафыннан Килешү түбәндәге очракта бер яклы булып өзелә ала:

- укучының 15 яше тулган очракта, тәртибе буенча мәктәптән чыгарылган очракта;

- Түләүле белем бирү хезмәтенә вакытында түләмәсә;

- Түләүле белем бирү хезмәтен укучыга күрсәтеп булмаган очракта
( укучы теләми).

5.9.Заказчының өстәмә белем алу хезмәтләреннән баш тартуы хезмәт күрсәтү күләмен киметү өчен чара була алмый.

5.10. Заказчы һәм Башкаручы арасында килеп чыккан низаг һәм бәхәсләр, ирекле рәвештә ике якның килешүе нигезендә хәл ителә, әгәр бәхәс чишелмәсә, Россия Федерациясе законнары нигезендә суд карары белән хәл ителә.

5.11. Белем бирү оешмалары җитәкчеләре түбәндәгеләр өчен тулысынча җаваплылык тота:

- түләүле белем бирү өлкәсендә хокукый норматив актларны исәпкә алу, кулланучылар хокукларын яклау турында закон, шулай ук гражданлык, хезмәт, административ һәм җинаять законнарын үтәргә бурычлы;

- түләүле белем бирүне оештыру һәм аның сыйфаты;

- түләүле белем бирү өчен алынган акчаларны максатчан куллану;

- түләүле белем бирүнең бәясен тәртиптә тоту;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә каралган башка гамәлләр;

5.12.Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтү дәверендә, законнарны төгәл үтәмәгәндә, оешма җитәкчесе, оешма хезмәткәрләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла һәм алар административ җаваплылыктан, зыяннарны каплаудан азат ителмиләр.

5.13. Нигезләмә, аның сыйфатын, шул исәптән түләү эшләрен төгәл алып бару, контрольдә тоту өчен "Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәгариф учреждениесе" җитәкчесе җаваплы.

5.14. Хокук бозулар күзәтелгән очракта, сыйфаты кимегәндә, мәгариф учреждениесе хокуклы:

- түләүле белем бирү хезмәтен тукталырга, суд карары нигезендә хәл ителергә;

- бу лицензияне биргән оешмага, Россия Федерациясе законнарын боза торган хезмәттән азат итүне сорап мөрәҗәгать итәргә;

Түләүле белем бирү хезмәте тарифларын формалаштыру

Түләүле белем бирү өчен тариф күләме нигездә, билгеле бер оешманың, өстәмә белем бирү өчен тотылган чыгымнарны каплау белән бәйле, бу очракта түләү бәясе яңа ресурслар китереп чыгара.Төгәл сумма бер укучыга түләүле хезмәт күрсәтү ярәмендә карала:

- түләүле белем алучыларның максималь исәбе, төркем яисә сыйныф һ.б.;
- укучыларның ниятләнгән төгәл саны;
- алдан алынган укучылар саны;

Әлеге хезмәтнең төгәл суммасы бер кулланучыга (Сун) түләүле хезмәт күрсәтү буенча билгеле бер өлеш чыгымнарны каплау, кулланучыларның барлык саныннан чыгып исәпләнә (К).

Сун= Су/К

Түләүле белем бирү хезмәтенең бәясе (Су) түбәндәге формула белән күрсәтелә:

Су= Сс+Ну+Ср,

бу очракта

Сс- түләүле белем бирүнең үзбәясе;

Ну- түләүле белем бирү өчен салым законнары нигезендә кабул ителгән салымнар күләме;

Ср - оешманың матди базасын яхшырту өчен бүлеп бирелгән акча (табыш). Бүлеп бирелгән акча белем бирү өчен һәм уку учреждениесен матди яктан яхшырту өчен тотыла. Материаль базаны үстерү өчен тотылган акча күләме үзбәядән чыгып 30% ка кадәр җитәргә мөмкин.

1. Билгеле бер мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле белемнең үзкыйммәте.

1.1. Түләүле белем бирүнең үзкыйммәтен (Сс) билгеләү өчен чыгымнарны экономик эчтәлегенә бәйле рәвештә туры (Рпр) һәм кыек (Ркосв) элементларга бүлеп карарга кирәк:

Сс =Рпр+Ркосв.

1.2. Туры чыгымнарга түләүле белем бирү хезмәте белән турыдан-туры бәйле чыгымнар керә:

1) педагогик хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү чыгымнары, алар Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы федераль норматив хокукый актлары белән бәйле. Укытучыларга хезмәт хакы түләү түбәндәге чыгымнарны үз эченә алып тора:

- хезмәт хакы күләме, оклад, тариф күләмен үстерү, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр;

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы федераль норматив хокукый актлар нигезендә каралган өстәмә түләүләр;

Килешү нигезендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә түләү Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы законнары нигезендә билгеләнә.

Укытучыларга хезмәт хакы түләү формуласы түбәндегечә:

ФОТ nn = (СТсәг.+ ПР) х Кчас,

ФОТ nn- укытучының айлык хезмәт хакы;

СТсәг.- 1 сәг.эш хакы;

Ксәг.- түләүле белем бирү өчен айлык сәг. саны

ПР- укытучының премиясе. Премия күләме бер сәгатьлек тариф ставкалары күләмендә 150 % ка кадәр билгеләнә.

Педагогик хезмәткәрләргә 1 сәгатьлек эш хакын түләү түбәндәге формула белән карала:

СТсәг.= СТ/Нвр

СТ- хезмәт хакын түләү турындагы нигезләмә нигезендә куелган ставка;

Нвр- норматив документлар нигезендә куелган бер айлык сәгатьләр саны нормасы;

2) Педагогик хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә, шул ук очракта үз эченә иминият чыгымнарын да ала. Хезмәт хакын түләү чыгымнары да Россия Федерациясе законнары белән бәйләнгән.

3) Матди чыгымнар уку кирәк-яраклары, җиһаз һәм башка әйберләр булдыру өчен тотыла.

Матди чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

МЗ=Фсм/ Т

Фсм- түләүле хезмәт күрсәтү өчен тотылган материалларның төгәл бәясе;

Т- материалларны куллану вакыты (ай)

4) Арендага алынган бина өчен түләү килешү нигезендә билгеләнә.

Туры чыгымнарга аренда өчен түләү түбәндәге очракларда карала, әгәр аренда түләве түләүле белем бирү хезмәте күрсәтелгән очракта түләнсә. Түләүле белем бирү хезмәте билгеле бер вакытта күпме үтәлү күләменә карап, чыгымнар билгеләнә. Туры чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләнә:

Рnр= ФОТnn+ Hnn+ МЗ+Аn.

1.3. Кыек чыгымнарга түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтү өчен тотылган чыгымнар керә. Кыек чыгымнар булып түбәндәгеләр карала:

1) оешма хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү җитәкчеләрнең хезмәт хакы, админстратив-хуҗалык, уку-укыту һәм кече хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләргә түләү күләме, шул исәптән өстәмә түләү һәм кызыксындыру өчен түләүләр белән бәйле;

Килешү буенча эшләүче оешма хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү.

2) хезмәт хакын түләү күләме Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнә һәм страховка өлешенә каралган түләүләрне дә кертеп карый;

3) хуҗалык чыгымнары, (шул исәптән техник хезмәт күрсәтү системалары, видеокүзәтү системаларын саклау, санитария-эпидемиология хезмәте һ.б.) коммуналь чыгымнар, биналар өчен аренда чыгымнары;

Кыек чыгымнар үткән елгы фактик мәгълүмат чыгымнары аша ресурслар җитмәгәндә яисә киләсе ел өчен финанс яктан мәгълүмат чаралары булмаганда билгеләнә.

Бу чыгымнар норматив чыгымнарга өстәмә рәвештә мәгариф өлкәсендәге бюджет сметасы кысаларында карала.

4) башка чыгымнар да шулай ук үткән елгы чыгымнарга бәйле рәвештә яисә ресурс яктан тәэмин ителмәгән чакта, шулай ук киләсе ел өчен план әзерләгәндә кулланыла.

Кыек чыгымнарның формуласы түбәндәгечә:

Ркыек=ФОТоу+Ноу+Рх+Рбашка

Ркыек – кыек чыгымнар зурлыгы, алар үз эченә түләүле уку хезмәтенең үзкыйммәтен алып тора;

ФОТоу- оешма хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү;

Ноу- мәгариф учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү өчен исәпләнә;

Рх- хуҗалык чыгымнары;

Рбашка- башка чыгымнар.

Төгәл n-дәрәҗәсендәге өстәмә укытуның кыек чыгымнарының үзкыйммәте туры пропорциональ, һәм исәп-хисап коэффициенты аша билгеләнә:

Ркыек n=Рnрn х Ккр

Ркыек- кыек чыгымнар зурлыгы n-дәрәҗәсендәге түләүле уку хезмәтенең үзкыйммәте;

Рnрn- туры чыгымнарның зурлыгы, n-дәрәҗәсендәге өстәмә укытуның кыек чыгымнарының үзкыйммәте;

Ккр- кыек чыгымнар коэффициенты, үз эченә түләүле уку хезмәтенең үзкыйммәтен туры чыгымнарга бәйле рәвештә алып тора.

Кыек чыгымнарның коэффициенты алдагы чордагы фактик мәгълүматларга һәм киләсе ел өчен планнарга бәйле рәвештә карала:

Ккр= (ФОТоу+Ноу+Рбашка.

II . Өстәмә белем бирү хезмәтләренә бәяләр дискриминациясе.

2.1 Төрле төрдәге түләүле уку төренә ихтыяҗ үзенчәлеген, вакыт аралыгын исәпкә алып , мәгариф учреждениеләре төрле бәя куярга мөмкин.

2.2. Түләү хакын төшерергә дә мөмкин, әгәр дә икътисади эффект укучылар санын арттырса, дәрәҗәлерәк уку системасы булдырылса, түләүле белем алуда бәясе төшерелгән тарифлар коэффициенты уртача тариф күләменә ихтыяҗ таләп иткәндә.

2.3. Экстернат рәвештә түләүле уку хезмәтен булдыру, шулай ук бәйрәм һәм ял көннәрендә, төнлә уку очрагында түләү коэффициентын арттыру каралган.

2.4. Дискриминация коэффициентын исәпкә алып, түләүле хезмәт бәясе түбәндәге формула белән исәпләнә:

Суд= Суп х К

Суд- бер кулланучыга бәйле рәвештә түләүле уку хезмәтенең үзкыйммәте.

К- дискриминация коэффициенты.

Бәя дискриминация коэффициентын һәр мәгариф оешмасы үзе раслый һәм ул “Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәгариф учреждениесе” боерыгында күрсәтелергә тиеш.

3.1. Салым түләү күләме гамәлдәге салым (федераль, региональ һәм җирле) законнарына бәйле рәвештә билгеләнә.

Түләүле хезмәт өчен тариф чыгымнары

| | |
|---|---|
| Учреждение атамасы | |
| Хезмәтнең атамасы | |
| Үтәлү вакыты | |
| Айга ничә тапкыр | |
| 1 нче дәрес | |

| | |
|---|---|
| Дәреснең атамасы | |
| Айга ничә тапкыр | |
| 1 дәреснең үтәлү вакыты (мин) | |

1 эшче

| | |
|---|---|
| Укытучының квалификацион категориясе | |
| 1 айга билгеләнгән хезмәт хакы күләме | |
| Премия күләме (0-150%) | |
| Нигезләмә (НПА) | |
| Турыдан-туры ФОТка каралган 1 эшче өчен чыгымнар күләме | |
| Нигезләмә (НПА) | |
| 1 ставка өчен эш сәгате күләме | |

2 эшче

| | |
|---|---|
| Укытучының квалификацион категориясе | |
| 1 айга билгеләнгән хезмәт хакы күләме | |
| Премия күләме(0-150%) | |
| Нигезләмә (НПА) | |
| Турыдан-туры ФОТка каралган 2 эшче өчен чыгымнар күләме | |
| Нигезләмә (НПА) | |
| 1 ставка өчен эш сәгате күләме | |
| Төркемдә укучылар саны | |
| Турыдан-туры ФОТка бәйле рәвештә бер укучыга каралган сумма(сум/ай) | |

2 нче дәрес

| | |
|---|---|
| Дәреснең атамасы | |
| Айга ничә тапкыр | |
| 1 дәреснен үтәлү вакыты (мин) | |

1 эшче

| | |
|---|---|
| Укытучының квалификацион категориясе | |
| 1 айга билгеләнгән хезмәт хакы күләме | |
| Премия күләме(0-150%) | |
| Нигезләмә (НПА) | |
| Турыдан-туры ФОТка каралган 1 эшче өчен чыгымнар күләме | |
| Нигезләмә (НПА) | |
| 1 ставка өчен эш сәгате күләме | |

2 эшче

| | |
|---|---|
| Укытучының квалификацион категориясе | |
| 1 айга билгеләнгән хезмәт хакы күләме | |
| Премия күләме(0-150%) | |
| Нигезләмә (НПА) | |
| Турыдан-туры ФОТка каралган 2 эшче өчен чыгымнар күләме | |
| Нигезләмә (НПА) | |
| 1 ставка өчен эш сәгате күләме | |
| Төркемдә укучылар саны | |
| Турыдан-туры ФОТка бәйле рәвештә бер укучыга каралган сумма(сум/ай) | |

Туры чыгымнар

| | |
|---|---|
| Турыдан-туры ФОТка бәйле рәвештә 1 укучы га каралган, отпускны исәпкә алып саналган сумма (ай/сум) | |
| Айлык түләү күләме (30, 2%) (сум/ай) | |
| Бөтен төркем өчен каралган матди чыгымнар(сум/ай) | |

| Чыгымнар атамасы | Данәсе | Бәясе | Үтәлү вакыты | 1 айга каралган сумма |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

№ 129/ик « 16 » 05 2018 г.
отметка о регистрации в организационном отделе

# ЛИСТ СОГЛАСОВАНИЯ
проекта распоряжения Исполнительного комитета Буинского муниципального района

1.Наименоваание документа: Проект Постановления Исполнительного комитета Буинского муниципального района «Об утверждении Положения о порядке учета детей, проживающих на территории Буинского муниципального района Республики Татарстан и подлежащих обязательному обучению в образовательных организациях, реализующих программы общего образования»

2. Проект подготовлен: МКУ «Управление образования Буинского муниципального района» И.Ф. Ханбиков 3-26-02
(наименование структурного подразделения, организации, должность, ФИО исполнителя, телефон)

3. Представлен в организационный отдел: «16» 05 2018 г.

4. Окончательно согласован: «16» 05 2018 г.

5. Визы заместителей главы, руководителей структурных подразделений:

| Должность руководителя | Ф.И.О. | Дата передачи на согласование | Отметка о наличии (отсутствии) замечаний | Подпись, дата согласования, краткое содержание замечаний | Отметка об устранении замечаний, подпись и дата |
|---|---|---|---|---|---|
| Заместитель Главы Буинского муниципального района РТ | Е.А. Семагин | | | [подпись] | |
| Управляющая делами Исполнительного комитета Буинского муниципального района РТ | М.М. Юнусова | | | [подпись] | |
| Юридический отдел | А.М. Сафин | | | [подпись] | |

6. Передано на доработку: ______________________
(дата, от кого)

7. Передано на подпись: 16.05.2018 [подпись]
( дата, виза организационного отдела)

8.Зарегистрировано: 16.05.2018 [подпись] (Юнусова М.М.)
( дата, виза организационного отдела)